**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**23.03.2016** № **09-16-42**

Казан ш.

Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 6 июлендәге 09-16-88нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы сатып алулар һәм бәхәсләрне көйләү буенча Дәүләт комитетының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү комиссиясе турындагы Положениегә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт хезмәте вазифаларын башкаручы затларның вазифадагы бурычларын башкарганда бәхәс китереп чыгарган яисә чыгарырга мөмкин булган очракта хәбәр итү тәртибе һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында**»гы** 650нче Указына ярашлы рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 6 июлендәге 09-16-88нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы сатып алулар һәм бәхәсләрне көйләү буенча Дәүләт комитетының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү комиссиясе турындагы Положениегә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4нче пунктта «Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан алып барыла) дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан алып барыла)» дигән сүзләр белән алыштырырга;

5нче пункт үз көчен югалткан дип танырга;

8нче пунктның «б» подпунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«б) коррупциягә каршы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Президенты Идарәсе һәм (яисә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчә вәкиле;»

8нче пунктның «в» подпунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«в) эшчәнлеге дәүләт хезмәте белән бәйле булган урта, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре һәм фәнни оешмалар вәкиле

(вәкилләре).»

10нчы пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Әлеге Положениенең 8нче пунктларындагы «б» һәм «в» подпунктларында һәм 9нчы пунктта күрсәтелгән затлар Дәүләт Комитеты рәисе запросы нигезендә ярашлы органнар һәм оешмалар килешүе буенча тиешле тәртиптә Комиссия составына кертеләләр.»

11нче пунктта «дәүләт хезмәтләре» сүзләреннән соң «Дәүләт комитетында» сүзен өстәргә;

16нчы пунктның «б» подпунктының 2нче абзацында «башкарырга ризалык бирү турында» сүзләреннән соң «хезмәт килешүе шартларында» сүзләрен өстәргә;

16нчы пунктның «б» подпунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«вазифадагы бурычны үтәгәндә яклар арасында бәхәсләргә китергән яисә китерү мөмкинлеге турында дәүләт хезмәткәренә хәбәр итү;»;

17.1 пунктыннан дүртенче җөмләне алып ташларга;

17.3 пунктыннан икенче җөмләне алып ташларга;

17.4 пунктын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«17.4. Әлеге Положениенең 16нчы пунктының «б» подпунктындагы бишенче абзацта күрсәтелгән уведомленине карау нәтиҗәләре буенча мотивацияләнгән әзерлек алып баручы, коррупция һәм башка хокук бозулар профилактикасы буенча эшләргә җаваплы зат – кадрлар эше производствосын оештыручы һәм алып баручы хезмәткәр тарафыннан карала.»;

Түбәндәге эчтәлектәге 17.5 пункты белән тулыландырырга:

«17.5. Әлеге Положениенең 16нчы пунктының «б» пунктындагы икенче абзацта күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча яисә әлеге Положениенең 16нчы пуктындагы «б» подпунктының икенче абзацында һәм «д» подпунктында күрсәтелгән уведомлениеләр нигезендә ясалган мотивацияле нәтиҗә ясаучы кадрлар эше производствосын оештыру һәм алып баруга җаваплы хезмәткәр - коррупция һәм башка хокук бозу профилактикасы буенча эш өчен җаваплы затның мөрәҗәгать иткән яисә уведомление биргән дәүләт хезмәткәре белән сөйләшүләр алып барырга, аңардан язма аңлатма алырга хокукы бар, ә Дәүләт комитеты рәисе яисә рәис урынбасары, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга күрсәтелгән тәртиптә запрослар җибәрә ала. Мөрәҗәгать яисә уведомление һәм шулай ук ясалган нәтиҗә һәм башка материаллар килгән көннән алып җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла.

Запрослар җибәрелгәндә мөрәҗәгать яисә уведомление һәм шулай ук башка материаллар комиссия рәисенә мөрәҗәгать яисә уведомление килгән көннән алып 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма ул 30 көннән артмаска тиеш.»;

18нче пунктның «а» подпунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«а) комиссия утырышын 10 көн вакыт эчендә билгели. Шул ук вакытта

комиссия утырышы датасы әлеге информация килгән көннән алып 20 көннән соңга калмыйча билгеләнергә тиеш, әлеге Положениенең 18.1 һәм 18.2нче пунктларында каралган очракларда гына бу срок үзгәртелергә мөмкин;»;

18.1 пунктындагы «өченче абзацта күрсәтелгән гаризалар» сүзләрен «өченче һәм дүртенче абзацларда күрсәтелгән гаризалар» сүзләре белән алыштырырга;

19нчы пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«19. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм (яисә) яклар арасындагы бәхәсне көйләү турында таләпләр үтәү турында мәсьәлә карачы дәүләт хезмәткәре яисә Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазифасын башкаручы катнашында үтәрелә. Комиссия утырышында үзенең катнашырга теләге барлыгы турында дәүләт хезмәткәре яисә гражданин әлеге Положениенең 16нчы пунктындагы «б» подпунктына ярашлы рәвештә мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә уведомлениедә күрсәтә.»;

Түбәндәге эчтәлектәге 19.1 пункты белән тулыландырырга:

«19.1. Комиссия утырышлары дәүләт хезмәткәре яисә гражданин булмаганда түбәндәге очракларда үткәрелергә мөмкин:

а) әгәр дә әлеге Положениенең 16нчы пунктындагы «б» подпунктында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә уведомлениедә дәүләт хезмәткәренең яисә гражданинның комиссия утырышында шәхси катнашырга теләге булу турында күрсәтелмәгән булса;

б) әгәр дә дәүләт хезмәткәре яисә гражданин комиссия утырышында үзе катнашырга теләп һәм комиссия утырышының кайда һәм кайчан үткәрелүе турында хәбәр ителеп тә комиссия утырышына килмәсә.»;

түбәндәге эчтәлектәге 25.3 пункты белән тулыландырырга:

«25.3. Әлеге Положениең 16нчы пунктындагы «б» подпунктындагы бишенче абзацта күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре вазифадагы бурычын үтәгәндә яклар арасында бәхәс чыкмый дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре вазифадагы бурычын үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык яклар арасында бәхәс тудыра һәм тудырырга мөмкин дип танырга. Бу очракта комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яисә) Дәүләт комитеты рәисенә яклар арасындагы бәхәсне көйләү яисә аның барлыкка килү мөмкинлеген булдырмау буенча чаралар күрүне тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре яклар арасында каршылыкларны көйләү турында таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Бу очракта комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның конкрет чараларын күрергә киңәш итә.»;

«16нчы пунктның «а», "б", "г" һәм "д" подпунктларында» 26 сүзне «16нчы пунктның «а» - «д» подпунктларында» дигән сүзләр һәм «22 – 25, 25.1, 25.2 һәм пунктлары белән» дигән сүзләрне «22 – 25, 25.1 – 25.3 һәм пунктлары белән» сүзләре белән алыштырырга»;

Пунктта «3-көнлек срок» 33 сүзне «7-көнлек срок» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Рәис О.А.Редько